| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ<br>КОМИТЕТ<br>ЧЕРЕМШАНСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОНЫ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

22.12.2025 **Чирмешән авылы** **№ 415**

**Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитетының 2023 елның 25 октябрендәге «Чирмешән муниципаль районында өч һәм аннан да күбрәк савым сыеры булган шәхси хуҗалык алып баручы гражданнарга саву аппараты сатып алу чыгымнары өлешен каплауга 2023 елда Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 305 номерлы карарының үз көчен югалтуын тану хакында**

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитеты **КАРАР БИРӘ:**

1. Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитетының 2023 елның 25 октябрендәге «Чирмешән муниципаль районында өч һәм аннан да күбрәк савым сыеры булган шәхси хуҗалык алып баручы гражданнарга саву аппараты сатып алу чыгымнары өлешен каплауга 2023 елда Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 305 номерлы карарын үз көчен югалткан дип таныргa.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад мәсьәләләре буенча урынбасары Л.Г. Мортазинага йөкләргә.

Башкарма комитет
җитәкчесе И.М. Җамалетдинов